Ел саен Темник районы физик момкинчелекләре чикле булган балалар очен интернат-йортта инвалидлар декаднигы vткәрәләр. Декадникны йомгаклап зур бәйрәм – «Йорәктән-йорәккә» хәйрия (благотворительный) марафоны нәтижәләре буенча оештырыла.
Балалар, тәрбиячеләре белән бергә, зур сәхнәдән Мәскәvле, Саранскլы, Саровлы шәфкатьле, мәрхәмәтле, рәхимле, балалар тормышына битараф булмаган иганәчеләренә рәхмәтләрен белдерделәр. Аларны кvреп беләләр, еш очрашалар. Шундый кvрешvләр-очрашулар дуслыкны ныгыта, якынайта.   Шуна марафон алдыннан Темник интернат-йортына Дальний Восток - Комсомольск-на-Амурдан килеп тәрбияләнә торган Данил Бобровник иганәче Н. А. Леонтьева (ВНИИЭФ г. Саров) белән якыннарча аралашып алдылар. Данил аны vз итеп тетя Надя дип йортә. Чыннан да, монәсәбәтләр йорәктән-йорәккә кvчкән.
Данил Темник районы физик кимчелекле балалар очен интернат-йортында дvрт ел яши инде. Ул биредә икенче оендәгечә vзен хис итә; тәрбиячеләре, укытучылары, медицина хезмәткәрләре, дуслары – Татарстаннан Стас Тарасов, Тvбән Янашәһәрдән Артем Семинюков, Владимирдан Кирилл Усов, кыргызстаннан Айсылу Айткулов белән бер гаилә буларак торалар. Бу балалар барысы да инвалид-колясочниклар һәм барысы да яшьтәшләр дияргә була.
18 яшьлек Сергей Иванов (Саха-Якутиядән) фотографияләр белән кызыксына, марафон фотографияләрен ул тошерде, тарих очен. «Биредә дус яшибез, бер-беребезгә ярдәмләшеп һәм яхшылыкнын кадерен белеп»,- ди ул.
«В настоящее время в детском доме 22 воспитанника. Они получают все необходимые услуги: бытовые, медицинские, трудовые, правовые», - марафонны йомгаклау кичәсендә Темников балалар йорты директоры В. С. Кукушкин, ди. - Наша страна сейчас переживает экономический кризис. Итог тому - недофинансирование. Но наши воспитанники благодаря спонсорской помощи не чувствуют себя ущемленными. В этом году детский дом дополнительно получил 800 тысяч рублей. Эти средства направлены на приобретение лекарств, одежды, мебели. Кроме постоянной поддержки со стороны Минсоцзащиты населения РМ в лице министра И. В. Князькова, администрации Темниковского муниципального района, в организации жизнеобеспечения учреждения неоценимую помощь оказывают друзья из 16-го отделения ВНИИЭФ г. Сарова

(руководитель Л. В. Шляпникова). Каждый их приезд - это продуманная программа, где все дети задействованы по интересам. Шефы участвуют в воспитании детей-инвалидов, по-родительски заботятся о каждом выпускнике, поддерживая с ними контакты и участвуя в их судьбе».
Бәйрәм булгач, концерт була да була. Биредә зур концертны Йортта тәрбияләнvчеләр, тәрбиячеләре белән һәм район кунаклары кvрсәтте.
Район суды рәисе И. А. Сюлин чыгышында балалар белән аралашу беренче чиратта олыларга кирәк, ди. Чонки аларнын чиста йорәкләре доньягә башка кvзләр белән карарга ярдәм итә; шундый балаларны ишетә белергә тиешбез, дип кинәш итте чыгышында. Ул, чыгышын йомгаклап, Темник районы физик момкинчелекләре чикле булган балалар очен интернат-йорттагы инвалид-колясочник балаларга унышлар теләде чыгышында ул. Яна район житәкчесе С. Н. Кизим да залдагы урнашкан яхшылыкны, сафлыкны, балаларнын якты кvнелле булуларын билгеләп vтте. Без алар алдында бурычлыбыз, ди.
Рәхимле кешеләребез эшләре белән матур. Яна ел бәйрәмен тантаналы vткәрv урынына, ОО “Аграрный ресурс» предприятиясе, Руслан Мухаев житәкчелегендә, Темник районы физик момкинчелекләре чикле булган балалар очен интернат-йорттагы инвалид-колясочник балаларга торле уеннар, уенчыклар сатып алып марафон кысаларында бvләк иттеләр. Бергәләшеп, алар белән озак аралашып, хәтта алып килгән остәл уеннарын уйнап кайттылар. Мәрхәмәтле эштән татарларыбыз читтә калмый..

Наилә Насырова